ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, ТР Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
422700, Высокогорский район РТ, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82,e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**20 февраль 2015 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 175**

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районының
Красносельский авыл җирлеге
муниципаль берәмлек Уставына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге № 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 нче статьясы нигезендә, «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2002 нче елның 31 нче октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән (2014 нче елның 25 нче декабрендәге № 131-ТРЗ номерлы ТР Законнары редакциясендә), Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Уставын Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 86 нчы статьясындагы 3 нче өлешенә таянып, Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 33 нче статьяның 1 нчке өлешендәге 7 нче пунктында «Җирлекләр,» сүзләреннән соң «җирлекнең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын, җирлекнең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын» сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле 77 нче статьяның 9 нчы өлешендәге 6 нчы абзац өстәргә:

«- Җирлекнең норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару көне, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча аларның тулы текстын беренче булып бастырып чыгару (бастырып чыгару) «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» (PRAVO.TARSTAN.RU) нигезендә беренче тапкыр бастырып чыгару (бастырып чыгару) көне дип санала»;

3) 85 нчы статьяның 7 нче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлек бюджетлары проектларын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Россия Федерациясе Президенты юлламасы нигезләмәләре;

бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

Россия Федерациясе таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре;

социаль-икътисадый үсеш фаразы;

озак сроклы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразы проекты);

дәүләт (муниципаль) программалары (дәүләт (муниципаль) программалары проектлары, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектлары).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru бастырып чагарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Красносельский җирлеге башлыгы урынбасары Никитенко Р.Р.га йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районының
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин